БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16 декабрь 2020 ел № 32

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставын «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан һәм 2020 елның 2 ноябрендәге гавами тыңлаулар тәкъдимнәрен һәм Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2020 елның 19 ноябрендәге 02-976ЭП номерлы тәкъдимнәрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. 2016 елның 28 апрелендәге 37 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

**1) Уставның 6 статьясындагы 1 пунктының 16 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16) Район территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау), җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү буенча эшчәнлекне оештыруда катнашу;»;

**2) Уставның 6 статьяның 1 пунктындагы 40 пунктчасында** «күчемсез милек дәүләт кадастрында» сүзләрен «кадастр эшчәнлеге» сүзләренә алмаштырырга»;

**3) Уставның 7 статьясындагы 1 пунктын** түбәндәге эчтәлекле 13, 14 пунктлары белән тулыландырырга:

«13) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-I номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру»;

14) участок полициясе вәкаләтле вәкиле вазыйфасын биләп торучы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында торак урыны бирү.».

**4) Уставны** түбәндәге эчтәлекле **16.1 статьясы белән тулыландырырга:**

**«Статья 16.1. Инициативалы проектлар**

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне яки аларны хәл итү хокукы җирле үзидарә органнарына бирелгән башка мәсьәләләрне хәл итү буенча Район халкы яки аның өлеше өчен өстенлекле булган чараларны тормышка ашыру

максатыннан, Район башкарма комитетына инициативалы проект кертелергә мөмкин. Инициативалы проектлар гамәлгә ашырыла торган Район территориясенең бер өлешен билгеләү тәртибе Район Советы тарафыннан норматив хокукый акт белән билгеләнә.

2. Инициативалы проектны кертү инициативасы белән, уналты яшькә җиткән һәм Район территориясендә яшәүче кимендә ун гражданнан торган инициатив төркем, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, авыл торак пунктының старостасы (алга таба - проект инициаторлары) чыгыш ясарга хокуклы. Инициатив төркемнең минималь саны Район Советының норматив хокукый акты белән киметелергә мөмкин. Шулай ук Район Советының норматив хокукый акты нигезендә проект инициаторы булу хокукы Район территориясендә эшчәнлек алып баручы башка затларга да бирелергә мөмкин.

3. Инициативалы проект үз эченә түбәндәге мәгълүматларны алырга тиеш:

1) муниципаль берәмлекнең яисә аның бер өлешенең халкы өчен өстенлекле әһәмияткә ия булган проблеманың тасвирламасы;

2) әлеге проблеманы хәл итү буенча тәкъдимнәрнең нигезе;

3) инициативалы проектны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәсенең (көтелгән нәтиҗәләренең) тасвирламасы;

4) инициативалы проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле чыгымнарның башлангыч исәп-хисап;

5) инициативалы проектны гамәлгә ашыруның планлаштырылган сроклары;

6) әлеге проектны гамәлгә ашыруда кызыксынучы затларның планлаштырыла торган (мөмкин булган) финанс, мөлкәти һәм (яисә) хезмәт ягыннан катнашуы турында белешмәләр;

7) инициативалы проектны гамәлгә ашыру өчен, планлаштырылган инициатив түләүләр күләменнән тыш, әлеге акчаларны файдалану күздә тотылган очракта, җирле бюджет акчалары күләменә күрсәтмә;

8) Район Советының норматив хокукый актында билгеләнгән тәртип нигезендә инициатив проект гамәлгә ашырылачак Район территориясенә яисә аның өлешенә күрсәтмә;

9) Район Советының норматив хокукый актында каралган башка белешмәләр.

4. Район башкарма комитетына керткәнче, инициативалы проект, инициатив проект турында фикер алышу, аның Район халкы мәнфәгатьләренә туры килүен билгеләү, инициатив проектны гамәлгә ашыруның максатчанлыгын билгеләү, шулай ук гражданнар җыены, җыелышы яисә конференциясе тарафыннан инициатив проектны хуплау турында карар кабул итү максатларында, гражданнар җыенында, җыелышында яки конференциясендә, шул исәптән территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында яисә конференциясендә каралырга тиеш. Шул ук вакытта гражданнарның бер җыенында, бер җыелышында яки бер конференциясендә берничә инициативалы проектны карау мөмкин.

Район Советының норматив-хокукый акты белән гражданнарны сораштыру, аларның имзаларын җыю юлы белән дә инициативалы проектка ярдәм итү мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерен ачыклау мөмкинлеге каралган.

Проект инициаторлары инициативалы проектны Район Башкарма комитетына керткәндә аңа тиешенчә гражданнар җыенының, җыелышының яки

конференциясенең беркетмәсен, инициатив проектның Районның яисә аның өлешенең халкы тарафыннан хуплануын раслый торган гражданнарны сораштыру нәтиҗәләрен һәм (яки) имзалар кәгазен теркиләр.

5. Инициативалы проектны Район башкарма комитетына кертү турындагы мәгълүмат инициативалы проект Район башкарма комитетына кертелгәннән соң өч эш көне эчендә baltasi.tatarstan.ru районның рәсми сайтында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм урнаштырылырга тиеш һәм әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне, шулай ук проект инициаторлары турында белешмәләрне үз эченә алырга тиеш. Бер үк вакытта гражданнарга, биш эш көненнән дә ким булмаган тәкъдим итү вакытын күрсәтеп, Район башкарма комитетына инициативалы проект буенча үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен бирү мөмкинлеге турында хәбәр итәләр. Уналты яше тулган Район кешесе үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен җибәрергә хокуклы.

6. Инициативалы проект Район башкарма комитеты тарафыннан кертелгән көннән соң 30 көн эчендә мәҗбүри каралырга тиеш. Район башкарма комитеты инициативалы проектны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) инициативалы проектны хупларга һәм җирле бюджет проектын төзү һәм карау тәртибе (җирле бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү) нигезендә җирле бюджет турындагы карарда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә аның өстендә эшне дәвам итәргә;

2) инициативалы проектка ярдәм итүдән баш тартырга һәм инициативалы проектны хуплаудан баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, аны проект инициаторларына кайтарырга.

7. Район башкарма комитеты түбәндәге очракларның берсендә инициативалы проектка ярдәм итүдән баш тарту турында карар кабул итә:

1) инициатив проектны кертү һәм аны карауның билгеләнгән тәртибен үтәмәү.;

2) инициативалы проектның федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары таләпләренә, әлеге Уставына туры килмәве;

3) җирле үзидарә органнарында кирәкле вәкаләтләр һәм хокуклар булмау сәбәпле, инициативалы проектны гамәлгә ашыру мөмкинлеге булмау;

4) инициативалы проектны гамәлгә ашыру өчен кирәк булган акчалар күләмендә аларны формалаштыру чыганагы инициатив түләүләр булмаган җирле бюджет акчалары булмау;

5) инициативалы проектта тасвирланган проблеманы нәтиҗәлерәк ысул белән хәл итү мөмкинлеге булу;

6) инициативалы проектны конкурс нигезендә сайлап алуны узмаган дип тану.

8. Район башкарма комитеты, проект инициаторларына инициативалы проектны бергәләп эшләп бетерергә, шулай ук аны башка муниципаль берәмлекнең яки дәүләт органының җирле үзидарә органына аларның компетенциясе нигезендә тәкъдим итәргә хокуклы, ә әлеге статьяның 3 пунктында каралган очракта - тәкъдим итәргә тиеш.

9. Инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу, карау, шулай ук аларны конкурс нигезендә сайлап алу тәртибе Район Советы (Район Советы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы гражданнар җыены) тарафыннан билгеләнә.

10. Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар исәбенә финанс ярдәме алу өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларга карата инициатив проектларда булырга тиешле белешмәләр составына таләпләр, инициатив проектларны карау тәртибе, шул исәптән аларны хуплаудан баш тарту өчен нигезләр, мондый инициатив проектларны конкурс нигезендә сайлап алу тәртибе һәм критерийлары Татарстан Республикасы законы һәм (яисә) башка норматив хокукый акты нигезендә билгеләнә. Бу очракта әлеге статьяның 3 пунктындагы таләпләр кулланылмый.

11. Әгәр Район башкарма комитетына берничә инициатива проекты, шул исәптән эчтәлеге буенча шундый ук өстенлекле проблемаларны тасвирлау белән, кертелгән булса, Район башкарма комитеты конкурс нигезендә сайлап алуны оештыра һәм бу хакта проектның инициаторларына хәбәр итә.

12. Инициатив проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү аларны төзү һәм аларның эшчәнлеге тәртибе Район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә торган коллегиаль органга (комиссиягә) йөкләнә. Коллегиаль орган (комиссия) составы Район башкарма комитеты тарафыннан төзелә. Шул ук вакытта коллегиаль орган (комиссия) әгъзаларының гомуми саныннан яртысы Район Советы тәкъдимнәре нигезендә билгеләнергә тиеш. Проект инициаторларына һәм аларның вәкилләренә конкурс нигезендә сайлап алуны уздырганда коллегиаль орган (комиссия) тарафыннан инициативалы проектларны карауда катнашу һәм алар буенча үз карашын бәян итү мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.

13. Проектның инициаторлары, Район территориясендә яшәүче гражданнар, гражданнар җыены, җыелышы яисә конференциясе тарафыннан вәкаләтле затлар, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнә торган башка затлар Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган рәвешләрдә инициативалы проектны гамәлгә ашыруны иҗтимагый контрольдә тотарга хокуклы.

14. Район Башкарма комитетының инициативалы проектын карау, инициативалы проектны гамәлгә ашыруның барышы, шул исәптән акчаларыннан файдалану, аны тормышка ашыру белән кызыксынучы затларның мөлкәти һәм (яки) хезмәт катнашуы турында мәгълүмат baltasi.tatarstan.ru районның рәсми сайтында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм урнаштырылырга тиеш. Җирлек Башкарма комитетының инициативалы проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турындагы хисабы инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәмамланганнан соң 30 календарь көн эчендә җирлекнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) һәм урнаштырылырга тиеш.

**5) Уставның 18 статьясындагы 1 пунктын** «һәм Район җирле үзидарәсенең вазыйфаи затларын» сүзләреннән соң «инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча фикер алышу» сүзләре белән тулыландырырга,»;

**6) Уставның 18 статьясындагы 2 пунктын түбәндәге абзац белән тулыландырырга:**

«Инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында уналты яшькә җиткән тиешле территориядә яшәүчеләр катнашырга хокуклы. Инициатив проектларны кертү мәсьәләләрен карау һәм карау максатларында, гражданнар җыелышын билгеләү һәм уздыру тәртибе Район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.»;

**7) Уставның 20 статьясындагы 2 пунктын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:**

«Гражданнарның инициативалы проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча үткәрелгән сораштыруда инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителгән Районда яки аның өлешендә яшәүче уналтынчы яшькә җиткән затлар катнашырга хокуклы.»;

**8) Уставның 20 статьясындагы 3 пунктын түбәндәге эчтәлекле 3 пунктчасы белән тулыландырырга:**

«3) уналты яшькә җиткән инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителгән Районның яисә аның бер өлешенең халкы - әлеге инициативалы проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен.»;

**9) Уставның 20 статьясындагы 5 пунктында беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«5. Гражданнарны сораштыру билгеләү турындагы карар Район Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен Районның рәсми сайты файдаланылырга мөмкин. Район Советының гражданнарны сораштыру билгеләү турында норматив хокукый актында билгеләнә:»;

**10) Уставның 20 статьясындагы 5 пунктын түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча белән тулыландырырга:**

6) Районның рәсми сайтыннан (baltasi.tatarstan.ru) файдаланып, гражданнар арасында сораштыру уздырган очракта сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе»;»

**11) Уставның 20 статьясындагы 7 пунктының 1 пунктчасын** «яисә Район халкы» сүзләре белән тулыландырырга;

**12) Уставның 26 статьясындагы 2 пунктын** түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Район Советы депутатына, үз вәкаләтләрен даими булмаган рәвештә гамәлгә ашыру өчен, эш урынын (вазыйфаларын) айга ике эш көнен саклап калу гарантияләнә.

**13) Уставның 26 статьясындагы 6 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы Район Советы депутаты түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) эшкуарлык эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2) коммерция оешмасы яки коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә, түбәндәге очраклардан тыш, катнашырга:
а) сәяси партия, профсоюз органы, шул исәптән җирле үзидарә органында,

Районның сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән түләүсез нигездә идарәдә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашу;

б) Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына (Татарстан Республикасы Премьер-министрына) алдан хәбәр итеп, коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, профсоюз органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, Районның сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә катнашудан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашудан тыш) түләүсез нигездә катнашу;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында Район мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) оештыручысы (акционеры, катнашучысы) Район булган идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә, Район исеменнән оешманы оештыручының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә Район мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яки күзәтчелек советлары,коммерциягә карамаган чит ил хөкүмәтнеке булмаган оешмаларның һәм Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган аларның структур бүлекчәләренең башка органнары составына керергә.».

**14) Уставның 37 статьясын** түбәндәге эчтәлекле **6 пункты белән тулыландырырга:**

«6. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясындагы 7 өлешенең 2 пунктындагы «б» пунктчасында һәм «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 3.5 өлешенең 2 пунктында каралган очракларда җирлек башлыгы түләүсез нигездә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 2 нче кушымтасы нигезендә, коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга хокуклы».

**15) Уставнын 43 статьясындагы 1 пунктның 7 пунктчасында 13 абзацын** «хокуклар» сүзеннән соң «төп аз санлы халыкларның һәм башка халыкларның» сүзләре белән тулыландырырга.

**16) Уставның 43 статьяның 1 пунктындагы 5 пунктчасына** түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

« - Район территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау), җыю, транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

**17) Уставның 43 статьясындагы 1 пунктының 3 пунктчасында 3 абзацындагы** «дәүләт күчемсез милек кадастры» сүзләрен «кадастр эшчәнлеге» сүзләренә алмаштырырга.

**18) 43 статьяның 2 пунктын** түбәндәге эчтәлекле **11, 12 пунктлар**ы белән тулыландырырга:

«11) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-I номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру;

12) участок полициясе вәкаләтле вәкиле вазыйфасын биләп торучы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында торак урыны бирү.».

**19) 84 статьяның 4 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Район Советының тиешле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм бюджет турында карар проекты кертелгәннән соң кабул ителгән муниципаль хокукый актлары нигезләмәләре агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә чираттагы финанс елында исәпкә алына.».

**20) Уставны** түбәндәге эчтәлекле **86.1 статьясы белән тулыландырырга:**

«86.1 Статья. Инициативалы проектларны тормышка ашыруны финанс һәм башка яктан тәэмин итү:

1. Әлеге Уставның 15.1 статьясында каралган инициативалы проектларны гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып җирле бюджет турындагы карарда каралган инициативалы проектларны гамәлгә ашыруга, шул исәптән, Районның тиешле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында бирелгән инициативалы түләүләр һәм (яисә) бюджетара трансфертларны исәпкә алып, формалаштырыла торган бюджет ассигнованиеләре тора.

2. Инициативалы түләүләр астында гражданнарның, шәхси эшкуарларның һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән юридик затларның ирекле нигездә түләнә торган һәм конкрет инициативалы проектларны гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә җирле бюджетка күчерелә торган акчалар аңлашыла.

3. Әгәр дә инициативалы проект гамәлгә ашырылмаган булса, инициативалы түләүләр аларны җирле бюджетка күчерүне гамәлгә ашыручы затларга (шул исәптән оешмаларга) кире кайтарылырга тиеш. Инициативалы проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча инициативалы проектны гамәлгә ашыру максатларында файдаланылмаган инициативалы түләүләр калган очракта, күрсәтелгән түләүләр аларны җирле бюджетка күчерүне гамәлгә ашыручы затларга (шул исәптән оешмаларга) кире кайтарылырга тиеш.

Аларны жирле бюджетка күчерүне гамәлгә ашыручы затларга (шул исәптән оешмаларга) кире кайтарылырга тиешле инициативалы түләүләр суммаларын исәпләү һәм кире кайтару тәртибе Район Советының норматив хокукый акты (Район Советы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы гражданнар җыены карары белән) белән билгеләнә.

4. Инициативалы проектларны гамәлгә ашыру, шулай ук кызыксынган затларның ирекле мөлкәти һәм (яки) хезмәт катнашуы рәвешендә дә тәэмин ителергә мөмкин».

**21) Уставның 87 статьясындагы 1 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль эчке бурыч алулар дигәндә Район исеменнән муниципаль кыйммәтле кәгазьләр урнаштыру юлы белән һәм Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан һәм кредит оешмаларыннан Районның заем алучы буларак Россия Федерациясе валютасында белдерелгән бурыч йөкләмәләре барлыкка килә торган кредитлар рәвешендә Район бюджетына заем акчаларын җәлеп итү аңлашыла.».

**22) Уставның 90 статьясындагы 1 пунктының 1 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль финанс контроле бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлар, физик затларга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан гавами норматив йөкләмәләр һәм башка түләүләр буенча йөкләмәләр бирә торган хокукый актлар нигезләмәләрен, шулай ук бюджеттан акчалар бирү турында муниципаль контрактлар, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәүне тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.»;

**23) Уставның 90 статьясындагы 2 пунктында** «бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

**24) Уставның 90 статьясындагы 3 пунктында** «бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге карар, гамәлдәге законнарда үз көченә керүнең башка вакытлары каралган нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

4. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары Н.Н.Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин